Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы 18 нче катнаш балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү бюджет учреждениясе

# Серле перчатка

## 4-6 яшьлек рус балалары өчен дидактик уен



Гыйльметдинова Миләүшә Рәшит кызы,
югары квалификацион
категорияле
татар теле тәрбиячесе

**Максат:** УМК кысаларында өйрәнгән сүзләрне ныгыту. Аралашу теләге тудыру. Татар теленә кызыксыну уяту

## 1 ысул “Сорап ал”

**Уен барышы:**

Алып баручы “Серле перчатка” кия, узе янына бер баланы чакыра. Бала үзе теләгән әйберне “Серле перчатка”дан сорап ала.

***Искәрмә:*** *“Серле перчатка”га гаилә әгъзасының рәсеме беркетелә, бала гаилә әгъзасы роленә кереп сораган әйберне бирә.*

**Сөйләм үрнәге:**

**-Миңа кишер бир әле? (Әти, миңа кишер бир әле?)**

**-Нинди кишер?**

**-Тәмле, чиста кишер.**

**-Мә, тәмле, чиста кишер.**

**-Рәхмәт.**





## 2 ысул “Мә”

**Уен барышы:**

Алып баручы “Серле перчатка” кия, бер гаилә әгъзасының рәсемен перчаткага беркетә, үзе янына бер баланы чакыра. Бала үзе теләгән ашамлыкны бу гаилә әгъзасына бирә.

**Сөйләм үрнәге:**

**-Бабай, мә кәбестә. Кәбестә тәмле, зур, яшел, баллы.**



## 3 ысул “Сыйла”

**Уен барышы:**

Алып баручы “Серле перчатка” кия, бер гаилә әгъзасының рәсемен перчаткага беркетә, үзе янына бер баланы чакыра. Бала үзе теләгән ашамлык белән бу гаилә әгъзасын сыйлый.

**Сөйләм үрнәге:**

**-Әни, мә суган. Әни суган аша.Суган тәмле, зур.**



## 4 ысул “Ничә?”

**Уен барышы:**

Алып баручы бер төрле яшелчәләр беркетелгән “Серле перчатка” кия, үзе янына бер баланы чакыра. Бала алып баручыдан перчаткага беркетелгән яшелчәне сорый, ә алып баручы “Ничә?” соравы аша ничә яшелчә кирәклеген ачыклый һәм санап яшелчәләрне бирә.

**Сөйләм үрнәге:**

**-Миңа кыяр бир әле.**

**-Ничә кыяр?**

**-Ике кыяр.**

**-Мә, ике кыяр.**

**-Рәхмәт.**

